| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕНЫРТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ НЫРТЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| 422063, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Большие Нырты, ул. М.Джалиля, 13а<br>тел. (84362) 45-2-32 | 422063, Татарстан Республикасы, Саба районы, Олы Нырты авылы, М.Җәлил урамы, 13а йорт<br>тел. (84362) 45-2-32 |

e-mail: Bnir.Sab@tatar.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

23.04.2019 — № 9

Саба муниципаль районы Олы Нырты
авыл җирлеге җирле үзидарә органнары
тарафыннан күрсәтелүче муниципаль
хезмәтләр исемлеген раслау турында

“ Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатында, Татарстан республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәтләр исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге башкарма комитетының 01.06.2011 елгы №12 “Җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында” карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/rus/, җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Олы Нырты авыл җирлеге башлыгы: Р.З.Сәфәргалиев

Олы Нырты авыл җирлеге
башкарма комитетының
23.04.2019 елгы №9
карары белән РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге

| | |
|---|---|
| 1 | Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару |
| 2 | Документларның күчермәләрен һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау |
| 3 | Нотариаль гамәлләр кылу: васыятьнамә яки ышанычнамәләрне раслау |
| 4 | Белешмәләр (өземтәләр) бирү |
| 5 | Агачлар яки куаклыкларны кисәргә, төпләргә яки утыртырга рөхсәт бирү |
| 6 | Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу |
| 7 | Муниципаль торак фондыннан гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү |
| 8 | Муниципаль торак фондындагы торак урыннарын гражданнарга хезмәт торак урынын найм шартнамәләре буенча бирү |
| 9 | Төзелеп беткән территорияләрне үстерү өчен җир кишәрлекләре бирү |
| 10 | Торак төзелеше максатларында аны комплекслы үзләштерү өчен муниципаль милектә булган җирләрдән җир кишәрлеген арендалау шартнамәләрен төзү хокукын сату буенча торглар оештыру һәм үткәрү |
| 11 | Күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү |
| 12 | Җирлектәге муниципаль милектәге биналарны, корылмаларны һәм торак булмаган биналарны арендага бирү |